
# «ВОСХОД» ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ИНСТИТУТЫ» ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫН МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ

ВОСХОД
www.voskhod.ru

# Гомуми мәгълүматлар

«Восход» - ФТИ ФДБУ - мәгълүмат технологияләре өлкәсендә дәүләтнең мультисервис партнеры: без хакимият органнары өчен инновацион ИТ-чишелешләр булдырабыз, дәүләт һәм җәмгыять арасында нәтиҗәле үзара бәйләнешнең яңа форматларын гамәлгә кертәбез һәм камилләштерәбез.



«Восход» — Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы карамагындагы предприятие.




Без, хакимият органнары арасында мәгълүмат алмашуның нәтиҗәле ысулларын эшкәртеп, гражданнар өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең уңайлы һәм гади интерфейсларын төзеп, дәүләткә мәгълүмати җәмгыять формалаштырырга булышабыз.

# «Восход» саннарда һәм фактларда

## ▪ 2298,95 млн. сум

2017 ел өчен табыш, НДСны исәпләмичә



- **34,6%** консалтинг һәм программа тәэминатының кастомизациясе
- **5,5%** заказлы программа тәэминатын эшләү
- **9,2%** инфраструктур хезмәтләр хостингы
- **5,0%** ИТ-консалтинг
- **45,7%** ИТ-системаларның аутсорсингы

*Чыганак: IDC Russia IT Services Market 2017*

- Tadviser һәм CNews Analytics версияләре буенча дәүләт секторын чишелешләр белән тәэмин итүчеләрнең ТОП-20нә керә.
- Берничә йөз проектны тормышка ашырды, шуларның 46сы - федераль дәрәҗәдәге системалар төзү һәм камилләштерү
- 630 югары квалификацияле хезмәткәр, шуларның 40ы гыйльми дәрәҗәләргә ия
- Уйлап табуларга, файдалы модель, программа тәэминатына 72 гамәлдәге патент һәм таныклык
- Мәгълүмат саклау, куркынычсызлык, телекоммуникация һ.б.лар өлкәсендә 20 дәүләт лицензиясе
- HeadHunter версиясе буенча ИТ-тармакның иң яхшы 30 эш бирүчесе исәбенә керә

# Эшчәнлек юнәлешләре

Мәгълүмат системаларын эшкәртү һәм эксплуатацияләү

Программа тәэминатын эшкәртү һәм гамәлгә кертү

Инфраструктура һәм мәгълүматлар белән идарә итү

Болыт технологияләре базасында чишелешләр

Фән һәм мәгариф

## Безнең принциплар

### Тулы цикл

Дәүләт стандартлары таләпләре нигезендә автоматлаштырылган системаларны эшкәртү, бөтен тормыш циклы барышында ярдәм һәм тәэмин итү.

### Җаваплылык

Куелган бурычларны берсүзсез үтәү өчен заказчылар һәм партнерлар каршында тулы җаваплылык

### Сыйфат

Башкарган эшләр сыйфатына карата эчке сәясәт, шулай ук Россия һәм халыкара стандартлар белән билгеләнгән югары таләпләр.

### Мәгълүмат куркынычсызлыгы

Мәгълүмат үтеп чыгуга юл куймау, конфиденциальлек һәм шәхси мәгълүматларны саклау буенча таләпләрне катгый үтәү, бу мәгълүмат саклау һәм криптография өлкәсендә дәүләт лицензияләре белән дә расланa.

### Импортны алыштыру

Геосәяси хәлгә бәйсез рәвештә системаның эшләвен тәэмин итү өчен, беренче чиратта, үз эшләнмәләрен һәм Россия җитештерүчеләренең югары технологияле җиһазларын куллану.

# Территориаль-бүленгән (катлаулы) ИТ-системаларны эшләү һәм кулланылышын тәэмин итү

Без тулысынча әзер катлаулы системалар төзибез, шулай ук партнерларның киң челтәре белән хезмәттәшлектә аерым эшләрне башкарабыз.




«Восход»ның уйлап табу һәм эксплуатацияләү өчен бөтен кирәкле ресурслары һәм компетенциясе бар:

- классик территориаль-бүленгән мәгълүмат системаларын, шул исәптән сакланган башкарылуда;
- мәгълүмат тапшыру һәм элемтә челтәрләренең бүленгән системаларын;
- интернет-порталлар һәм сайтларны;
- ситуацион һәм диспетчерлык үзәкләрен һәм идарә пунктларын;
- ведомствоара бәйләнеш системаларын;
- мәгълүмат эшкәртү үзәкләрен һәм контакт-үзәкләрне;
- төрле билгеләнештәге болыт сервисларын (IaaS, PaaS, SaaS);
- электрон документлар әйләнешен;
- заказчының мәгълүмат системалары эксплуатациясе белән идарә системаларын;
- мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү системаларын;
- дистанцион уку һәм персоналга тест уздыру системаларын.

# Программа тәэминатын эшләү һәм гамәлгә кертү

«Восход» традицион рәвештә югары компетенциясен раслый һәм заказлы программа тәэминатын эшләү өлкәсендә киң спектр хезмәтләр күрсәтә. Соңгы елларда гына да без федераль ведомствоара хезмәттәшлек системасын, бердәм норматив-белешмә мәгълүмат системасын, бердәм транспорт челтәре макетын һ.б эшләдек.




## Безнең хезмәтләр:

- мәгълүмат процессларын тикшерү, булачак мәгълүмат системасының концепциясен уйлап табу һәм проектлау;
- төрле платформаларда, шул исәптән Oracle, Microsoft ны кертеп, программа тәэминатын, төрле OpenSource продуктлар уйлап табу;
- болытлы исәпләүләр, өч буынлы һәм клиент-сервер архитектураларын кертеп, төрле функция модельләрендә программа тәэминатын гамәлгә кертү;
- программа тәэминатына аудит һәм тест уздыру.

# Инфраструктура һәм мәгълүматлар белән идарә итү



«Восход» заказчы системалары эксплуатациясен тәэмин итү, инфраструктура һәм мәгълүматлар белән идарә итү мәсьәләләрендә зур тәҗрибәгә һәм югары компетенциягә ия.

Бу өлкәдә безнең белгечләр киң спектрда хезмәт күрсәтә, шул исәптән:

- җиһазларга һәм программа тәэминатына техник ярдәм;
- мәгълүмат системаларын һәм комплексларын тәэмин итү;
- демонстрацион стендлар, төп конструктор стендлары һ.б.лар эшен оештыру һәм тәэмин итү;
- мәгълүматларның резерв күчермәсен алу һәм торгызу;
- мәгълүмат саклау һәм инфраструктура куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- дистанцион мониторинг һәм инфраструктура белән идарә системалары эшен оештыру һәм тәэмин итү;
- заказчы персоналын укыту һәм тест үткәрү;
- Help Desk һәм Service Desk хезмәтләрен кертеп, заказчының мәгълүмат системалары белән идарә итү.

# Болыт технологияләре базасында карарлар

Үз исәпләү куәтләре, алдынгы телекоммуникация структурасы һәм программалаштыру өлкәсендә компетенцияләре «Восход»ка болытлы исәпләүләр архитектурасы белән мәгълүмат системаларын булдыру һәм аларның эшен тәэмин итү буенча федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге проектларын уңышлы башкарырга мөмкинлек бирә, шул исәптән:

- «Восход» һәм аның партнерлары дата-үзәкләрендә заказчының болытлы мәгълүмат системаларын урнаштыру һәм аның эшен тәэмин итү буенча colocation, IaaS һәм PaaS хезмәтләре;
- болытлы мәгълүмат системаларын, шул исәптән интернет-порталлар, электрон документлар әйләнеше, болытлы проект офислары һәм коллектив эшчәнлек тәэмин итү системалары, норматив-белешмә мәгълүмат системалары һ.б.ларны урнаштыру һәм тәкъдим итү буенча SaaS хезмәтләре.



# Фән һәм мәгариф

45 ел дәверендә «Восход» саллы фәнни экспертиза туплады: институт портфелендә уйлап табулар, файдалы модель һәм программа тәэминатына 72 гамәлдәге патент һәм таныклык бар, ә командада гыйльми дәрәҗәле 40 хезмәткәр эшли.

Фәнни-белем бирү эшчәнлеге кысаларында «Восход» өч юнәлеш буенча эш алып бара:

## Фәнни-техник совет (ФТС)

Коллегиаль орган, ИТ өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашырганда, заманча фәнни карарларны гамәлгә керткәндә һәм бүлекчәләрнең эшчәнлеген координацияләгәндә карарлар кабул итү өчен фәнни-техник нигезне тәэмин итә. 1973 елдан бирле эшли, аның кысаларында 67 галимгә, шул исәптән «Восход»ның 55 хезмәткәренә фән докторы һәм кандидаты гыйльми дәрәҗәләрен биргән кадидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау буенча советлар гамәлдә булды.

## ИТ-кадрлар әзерләү өлкәсендә әйдәп баручы ВУЗларның база кафедралары

- МИРЭА — «Оештыру идарәсендә автоматлаштырылган системалар»;
- МЭСИ (Г.В.Плеханов ис.РЭУ) - «Территориаль-бүленгән мәгълүмат системалары»

«Восход» чыгарылыш студентларының гомуми һөнәри әзерлеген тәэмин итә, диплом алды практикасын, диплом проектларын һәм производство практикасын оештыра. Кафедра укытучылары - институтның әйдәп баручы экспертлары, "Восход"ның төп проектлары эшендә катнашучы мәгълүмат технологияләре тармагының гамәли профессионаллары.

## Заказчы персоналын әзерләү һәм сертификатлау

«Восход» эшләгән системалар составына кыска вакыт эчендә белгечләрне әзерләү һәм яңадан әзерләү процессын оештырырга гына түгел, укытуның дистанцион алымнарын һәм белемнәрне тикшерүнең интерактив системаларын кулланып, аларга сертификатлаштыру үткәрергә мөмкинлек бирүче ярдәмче системалар кертелгән.

# Ресурслар

## 630 хезмәткәр

## Мәгълүматларны эшкәртү үзәге:





- мәйданы  1400 м$^2$
- куәте 2000 кВА
- ышанычлылык дәрәҗәсе Tier-3
- 82 стойка
- төзелешнең дәүләт контроле
- режимлы объектта урнаштырылган
- физик куркынычсызлык, СКУД, видеокүзәтү
- гарантияле өзлексез электр белән тәэмин итү
- салкын тәэмин итү һәм автомат газ янгын сүндерү системалары
- автоматика һәм мониторинг системасы
- оптик СКС

## Инфраструктура:

- төрле билгеләнештәге электрон имзаны раслау үзәкләре
- «Мир» ДС һәм «Сайлаулар» ДАС модельләү стендлары
- шул исәптән "Мир" ДС ведомствоара резервлы мәгълүматлар эшкәртү үзәген кертеп, дәүләт системалары компонентлары
- "Мир" ДС кайнар линиясе
- дәүләт серен эшкәртү өчен аттестация узган чаралардан гыйбарәт режимлы-яшерен бүлек

# Төп проектлар һәм заказчылар

"Сайлаулар" дәүләт автоматлаштырылган системасы

Яңа буын паспорт-виза документларын әзерләү, рәсмиләштерү һәм контроле системасы

Прокуратура органнары һәм оешмаларының цифрлы трансформациясе

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (СМЭВ 3.0)

"Бәйсез регистратор" мәгълүмат системасы

Электрон хөкүмәтнең Федераль ситуацион үзәге

Төп раслау үзәгенең мәгълүмат системасы

Бердәм норматив-белешмә мәгълүмат системасы (ЕСНСИ)

ЕГИСЗ мәгълүматлар эшкәртү Федераль  үзәгенең төп мәйданчыгы

## Безгә ышаналар

Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы

Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы Федераль мәгълүматлаштыру үзәге

Генераль прокуратура

Эчке эшләр министрлыгы

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы

Оборона министрлыгы

Тышкы эшләр министрлыгы

Федераль Миграция Хезмәте

Транспорт министрлыгы

Сәламәтлек саклау министрлыгы

Федераль, төбәк һәм муниципаль хакимият һәм идарә органнары

# +7 (495) 981-88-99

ВОСХОД
www.voskhod.ru